**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 апрель № 269

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче, 2015 ел, 06 июль, 490 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.22 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.22. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының законнарда билгеләнгән очракларда, шул исәптән Казан шәһәре территориясе чикләрендә Татарстан Республикасы җирләре дәүләт резервына кертелгән җир кишәрлекләрен бирү турында карар проектларын әзерли һәм аларны сатудан һәм арендалаудан Татарстан Республикасы бюджетына акча керүне тикшерүдә тота.»;

3.3.23 пунктчага «законнарда каралган очракларда» сүзләреннән соң «җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукыннан баш тарту турында гариза нигезендә Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы туктатылу турында карар» сүзләрен өстәргә;

3.3.28 пунктчада «җир реформасы үткәреп» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3.46 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.46. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтында, шулай Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән сатуларны үткәрү турында мәгълүматны урнаштыру өчен рәсми сайтында дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын), дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карарны, әлеге мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары хакында мәгълүмати белдерүләрне, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында еллык мәгълүматны урнаштыруны тәэмин итә.»;

3.3.48 пунктчада «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

3.3.49 пунктчада «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

3.3.66 пунктчада «муниципаль берәмлекләр милкендәге» сүзләреннән соң «, шулай ук эш йөртү вәкаләтләре Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә тапшырылган,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.87 – 3.3.90 пунктчалар өстәргә:

«3.3.87. Аларда катнашу вазыйфаи йөкләмәләр башкару белән бәйле булган беркетмә чараларда, хезмәт командировкаларында һәм башка рәсми чараларда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау һәм аларның кыйммәтен билгеләүне, бу бүләкләрне сатуны (сатып алуны) гамәлгә ашыра.

3.3.88. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Җир кодексының 33[3] статьясы нигезендә сатулар үткәрмичә җир кишәрлекләрен бирү турында Татарстан Республикасы Президенты боерыклары проектларын әзерләүне гамәлгә ашыра.

3.3.89. Торак төзелешен үстерү буенча хөкүмәт комиссиясе карарлары нигезендә Россия Федерациясенең федераль милектәге җир кишәрлекләре белән, аларда урнашкан федераль милектәге күчемсез мөлкәт объектларын да кертеп, идарә итү һәм эш итү буенча Татарстан Республикасына тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

3.3.90. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 пункт нигезендә бирелгән дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра»;

4.3.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.5. Мәгълүматларны дәүләт күчемсез милек кадастрына кертү өчен Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасыннан файдаланып күчемсез милеккә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, кадастр исәбе һәм күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып бару өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына түбәндәгеләрне юллый:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында карарлар кабул ителгән очракта җир кишәрлекләренең категорияләре һәм аларны рөхсәт ителгән куллану өлешендә җир кишәрлекләре хакында белешмәләр үзгәрү турында мәгълүматны үз эченә алган әзер документлар архивын – XML-форматта һәм PDF-форматта әлеге карарларны күчермәләрен;

күчемсез милек объектларының дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләрен раслау турында карарлар кабул ителгән очракта күчемсез милек объектларының дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре турында белешмәләрне үз эченә алган әзер документлар архивын – XML-форматта;

муниципаль берәмлекләрнең чикләрен билгеләү яки үзгәртү турында Татарстан Республикасы законнары кабул ителгән очракта җир төзү объектларының карталарын (планнарын) үз эченә алган әзер документлар архивын – XML-форматта;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының җир кишәрлекләрен җирләрнең аерым бер категориясенә кертү турында карарлары күчермәләрен – PDF-форматта.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков